КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 март г.Казань № 235

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының календарь планнарына кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау тәртибен раслау турында» 2022 ел, 7 июль, 652 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының календарь планнарына кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының календарь планнарына кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау тәртибен раслау турында» 2022 ел, 7 июль, 652 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының календарь планнарына кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта:

алтынчы абзацта «туклануын,» сүзеннән соң «иминиятен,» сүзен өстәргә;

унынчы абзацта «сувенир продукциясе» сүзләреннән соң «, истәлекле призлар» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның өченче абзацында «туклануын,» сүзеннән соң «иминиятен,» сүзен өстәргә;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин